**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 елның «11» декабреннән № 86

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының «Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау буенча эш тәртибен раслау турында» 2008 елның 07 февралендәге 3 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында»**

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 27 ноябрендәге 355 – ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының «Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибен раслау турында» 2008 елның 7 февралендәге 3 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

- гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча эш тәртибенең «Гомуми нигезләмәләр»1 нче бүлегенә киләсе эчтәлектәге 1.12 пунктын өстәргә:

«Мөрәҗәгатькә җавап җирле үзидарә органнарына яисә вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә кергән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән электрон почта формасында һәм җирле үзидарә органнарына яисә вазыйфаи затка язмача мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән почта адресы буенча җибәрелә. Моннан тыш, тәкъдим, гариза яисә шикаять булган, билгесез затлар даирәсе мәнфәгатьләренә кагыла торган җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка кергән мөрәҗәгатькә, аерым алганда, билгеле булмаган затлар даирәсенә карата чыгарылган суд карарына шикаять бирелә торган мөрәҗәгатькә җавап, шул

исәптән суд карарына шикаять бирү тәртибен аңлатуга бәйле рәвештә, «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 27 ноябрендәге 355-ФЗ номерлы Федераль законының 6 статьясындагы 2 өлеше таләпләре үтәп, җирле үзидарә органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырылырга мөмкин»;

- гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча эш тәртибенең «Гомуми нигезләмәләр» исемле 1 нче бүлегенең 1.2 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 1.2.1. пунктын өстәргә:

«Җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә кергән мөрәҗәгать «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында»Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 27 ноябрендәге 355-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш»;

- гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча эш тәртибенең «Гомуми нигезләмәләр» исемле 1 нче бүлегенең 1.6 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 1.6.1. пунктын өстәргә:

«Язма мөрәҗәгать тексты буенча тәкъдимнең, гаризаның яки шикаятьнең асылын билгеләп булмаса, мөрәҗәгатькә җавап бирелми һәм ул җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка аларның компетенциясе нигезендә карап тикшерү өчен җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта мөрәҗәгатьне теркәгән көннән алып җиде көн эчендә мөрәҗәгатьне җибәргән гражданга хәбәр ителә.»;

- гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча эш тәртибенең «Гомуми нигезләмәләр» исемле 1 нче бүлегенең 1.6 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 1.6.2. пунктын өстәргә:

«Җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законның 10 статьясындагы 4 өлеше нигезендә «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2017 елның 27 ноябрендәге 355-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 4 өлеше нигезендә мәгълүмати һәм мәгълүмати яктан җирле үзидарә органының рәсми сайтында

урнаштырылган сорауны үз эченә алган язма мөрәҗәгать кергән очракта – «Интернет» телекоммуникация челтәре мөрәҗәгатен теркәгән көннән җиде көн эчендә «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтның электрон адресы хәбәр ителә, анда мөрәҗәгатьтә куелган сорауга җавап урнаштырылган, шул ук вакытта суд карары шикаятен үз эченә алган мөрәҗәгать кире кайтарылмый»;

2. Әлеге карарны Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталының «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында «http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы** **В.М. Козлов**